| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 25 май № 350

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 сентябрь, 661 нче; 2014 ел, 23 декабрь, 1014 нче; 2015 ел, 30 апрель, 309 нчы, 2015 ел, 31 декабрь, 1038 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган республика дәүләт статистикасы күзәтүенең № 1-контракт-рег (елга бер тапкыр) «Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү турында мәгълүматлар», № 1-инвест-рег (квартал) «Чит илдән инвестицияләр турында мәгълүматлар» формаларында, № 1-ДС (ярты ел) «Россия Федерациясе төбәкләреннән, чит илләрдән кертелә торган чимал һәм материаллар, комплектлаучы эшләнмәләр, полуфабрикатлар, ягулык-энергетика ресурслары (ЯЭР) турында мәгълүматлар» формасына кушымтада «Статистика мәгълүматын тапшыру тәртибен бозу, шулай ук дөрес булмаган статистика мәгълүматын кертү Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы 2001ел, 30 декабрь, ФЗ-195 нче кодексының 13.19 статьясы, шулай ук «Дәүләт статистикасы хисаплылыгын кертү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» 1992 ел, 13 май, 2761 – 1 нче Россия Федерациясе Законының 3 статьясы нигезендә җаваплылыкка китерә» сүзләрен «Респондетлар тарафыннан рәсми статистика исәбе субъектларына беренчел статистика мәгълүматларын билгеләнгән тәртиптә тапшырмау яки әлеге мәгълүматларны үз вакытында тапшырмау яисә дөрес булмаган беренчел статистика мәгълүматлар тапшыру Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 13.19 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка китерә. «Дәүләт статистикасы хисаплылыгын кертү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» 1992 елның 13 маендагы 2761-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясы нигезендә статистика органнарына дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә

яки хисап бирү вакытларын бозганда җыелма хисап нәтиҗәләрен төзәтү зарурлыгы белән бәйле барлыкка килгән зыян түләтелә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган республика дәүләт статистикасы күзәтүенең № ПМ (квартал) «Кече предприятие эшчәнлегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүматлар» формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган республика дәүләт статистикасы күзәтүенең № 1-бүлү (елга 1 тапкыр) «Эш хакы күләмнәре буенча хезмәткәрләр санын бүлү турында мәгълүматлар» формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган республика дәүләт статистикасы күзәтүенең № 1-нано (куллану) (квартал) «Нанотехнологияләргә бәйле булган нанокатнаш продукция (хезмәт күрсәтүләр) куллану турында мәгълүматлар» формасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 31 декабрь, 1038 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«№ 1-торак фонды-рег (еллык) «Торак фондыннан файдалану һәм аны саклауны тәэмин итү турында мәгълүматлар».»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгълүмат ресурсын (мәгълүматлар базасын) республика дәүләт статистикасы күзәтүенең «№ 1-торак фонды-рег (еллык) «Торак фондыннан файдалану һәм аны саклауны тәэмин итү турында мәгълүматлар» формасы нигезендә формалаштырырга.»;

карарга республика дәүләт статистикасы күзәтүенең «№ 1-торак фонды-рег (еллык) «Торак фондыннан файдалану һәм аны саклауны тәэмин итү турында мәгълүматлар» формасы өстәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен https://intra.tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурындагы «Мәгълүмати статистика ресурсы» автоматлаштырылган системасында яки «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты урнаштыра торган мәгълүмати материаллар исемлегендә:

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.7 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «2.7. | «Торак фондыннан файдалану турында мәгълүматлар» таблица материаллары | респуб-лика | елга 1 тапкыр | 25.04.2016»; |

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4.1. | «Республиканың башкарма хакимият органнары тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе үтәлеше мониторингы» таблица материалы | респуб-лика, ми-нистр-лыклар, ведом-стволар | кварт ал саен | 14.03.2016 (2015 елның гыйнвар – декабре өчен), 19.04.2016, 19.07.2016, 19.10.2016»; |

4.8 – 4.10 пунктларны төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган республика дәүләт статистикасы күзәтүенең 1-ДС (квартал) «Предприятиенең өстәлгән кыйммәте турында мәгълүматлар», 1 НП (елга 1 тапкыр) «Торак пункт турында мәгълүматлар», 1-һөнәри әзерләү (бер тапкыр) «Предприятие (учреждение, оешма) хезмәткәрләрен һөнәри әзерләү турында мәгълүматлар» формаларында «Статистика мәгълүматын тапшыру тәртибен бозу, шулай ук дөрес булмаган статистика мәгълүматын кертү Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы 2001ел, 30 декабрь, ФЗ-195 нче кодексының 13.19 статьясы, шулай ук «Дәүләт статистикасы хисаплылыгын кертү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» 1992 ел, 13 май, 2761 – 1 нче Россия Федерациясе Законының 3 статьясы нигезендә җаваплылыкка китерә» сүзләрен «Респондетлар тарафыннан рәсми статистика исәбе субъектларына беренчел статистика мәгълүматларын билгеләнгән тәртиптә тапшырмау яки әлеге мәгълүматларны үз вакытында тапшырмау яисә дөрес булмаган беренчел статистика мәгълүматлар тапшыру Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 13.19 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка китерә. «Дәүләт статистикасы хисаплылыгын кертү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» 1992 елның 13 маендагы 2761-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясы нигезендә статистика органнарына дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә яки хисап бирү вакытларын бозганда җыелма хисап нәтиҗәләрен төзәтү зарурлыгы белән бәйле барлыкка килгән зыян түләтелә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков